**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№12176**
**15.12.2023**

Башкарма комитетның 2022 елның 3 октябрендәге 5186 номерлы Карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 3 октябрендәге 5186 номерлы Карары белән (2023 елның 24 мартындагы 2090 номерлы, 2023 елның 9 июнендәге 4962 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасына, 2 бүлекнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә дәүләт яшьләр сәясәте Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе эшчәнлеге аша тормышка ашырыла, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 34 пункты нигезендә аңа балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен тормышка ашыруда, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны эшләүдә һәм тормышка ашыруда, яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, яшьләр сәясәтен тормышка ашыруны мониторинглауны оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу функцияләре йөкләнгән.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов